| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНы ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21 октябрь 2019 ел № 162

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 29 ноябрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2019 елның 14 октябрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы Идарәсенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бәяләмәсенә таянып, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 84, 85, 86 нчы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Чепья авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Чепья авыл
җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин